**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Россия көнен һәм Татарстан Республикасы көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия көнен һәм Татарстан Республикасы көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзү турында» 2017 елның 26 маендагы ПУ-441 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 22 декабрендәге ПУ-1153 номерлы, 2018 елның 19 февралендәге ПУ-177 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге ПУ-406 номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге ПУ-678 номерлы, 2020 елның 26 февралендәге ПУ-120 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы ПУ-233 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 5 июнендәге 386 указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Россия көнен һәм Татарстан Республикасы көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан А.В. Хохоринны, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына кертергә:

Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Садретдинов Дамир Рөстәм улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрын (килешү буенча);

в) оештыру комитеты әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Л.Р. Фазлыеваның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары»;

В.Г. Шәйхразиевның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 16 октябрь
№ 803